КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 апрель г.Казань № 235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче; 2022 ел, 25 июль, 716 нчы; 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче; 2023 ел, 21 март, 305 нче; 2023 ел, 2 июнь, 680 нче; 2024 ел, 29 март, 202 нче; 2024 ел, 30 май, 377 нче; 2024 ел, 4 декабрь, 1094 нче; 2024 ел, 21 декабрь, 1181 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның икенче абзацында «2024 елда Россия Федерациясендә Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасының бертип моделен гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 27 декабрендәге 895 номерлы» сүзләрен «2025 елда Россия Федерациясендә Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасының бертип моделен гамәлгә ашыру турында» 2024 елның 27 декабрендәге 732 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

5.7 пунктның 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2025 – 2027 елларда юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 25 декабрь, б-3099 нчы боерыгы белән расланган 2025 – 2027 елларда» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 24 декабрь, б-3012 нче боерыгы белән расланган 2025 елда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин